УДК 821.512.145
EDN CTHVGN

# Бөек Ватан сугышы чоры прозасында «окоп хакыйкате»

***Д. Ф. Зәһидуллина,***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов ис. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, Казан шәһ., Татарстан Республикасы, Россия Федерациясе*

# "Trench Truth" in the prose of the Great Patriotic War period

***D. F. Zagidullina,***

*G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, Kazan, the Republic of Tatarstan, the Russian Federation*

**Аннотация**

Статья посвящена «окопной правде» в татарской прозе периода Великой Отечественной войны. Безусловно, наиболее характерной особенностью прозы военного времени является ее героическое содержание. Поначалу, рассуждая о войне только из прочитанного и услышанного, писатели либо представляли ее в романтическом ключе, либо односторонне подходили к теме героизма, отдавая дань пропаганде и чувству патриотизма. Хотя в первых прозаических произведениях вера в победу, описание войны носили довольно схематичный характер, постепенно ситуация меняется: через перо прозаиков, сражавшихся на фронте, в татарскую литературу приходит окопная правда. Прозаиками, вызвавшими такое изменение в татарской литературе, были Габдрахман Абсалямов и Фатих Карим. В их литературных произведениях отчетливо прослеживается документальное начало: и повседневные бытовые хлопоты войны, и все детали выполнения боевой задачи, и то, как все это было спланировано и выполнено, описывается с особой детализацией. Ведь только точное правдивое описание событий, взятых из самой жизни, может обеспечить действенность литературы, ее воспитательную функцию. Наряду с героическим пафосом, в татарской литературе появляется национальный характер, образ храброго и отважного татарского человека. Образ татарского солдата, татарского человека, поставленный в центре каждого произведения, представляется образцом мужества, честности, верности, самоотверженности в борьбе за страну. На смену «массам» пришли такие понятия, как «татарский народ», «родная земля», «Отечество». На первое место выходит не гражданский долг, не классовая борьба, а борьба за жизнь, за страну, за любовь, за будущее. Таким образом, в литературе укрепляются гуманистические тенденции. Они остались в татарской литературе

и после окончания войны. Разделение образа жизни, мира на две противоположные грани, определяемые такими ценностями, как жизнь и смерть, свобода и рабство, мужество и трусость, позволяет ясно выразить позицию автора. В произведениях, воссоздающих окопную правду, разговор о духовной мощи, мужестве, человечности героев перерастает в разговор о человеке в целом, о его сущности, психологии, духовных и физических возможностях, а война – в величайшую трагедию, придуманную человечеством. Прозаики, привязанные к конкретному времени и месту, рассуждают об общечеловеческих ценностях. Даже после Великой Отечественной войны тема войны остается одной из главных в татарской литературе. Однако ее содержание меняется. По мере того, как мы отдаляемся от этой трагедии по времени, на смену окопной правде приходит изображение войны и человека в других плоскостях.

**Abstract**
This article is devoted to the "trench truth" in epy Tatar prose of the Great Patriotic War period. Undoubtedly, the most characteristic feature of wartime prose is its heroic content. At first, reasoning about the war only from what they had read and heard, writers either presented it in a romantic way or took a one-sided approach to the theme of heroism, paying tribute to propaganda and a sense of patriotism. Although in the first prose works the belief in victory and the description of the war were rather schematic, the situation gradually changed: trench truth came to Tatar literature through the pen of prose writers who fought at the front. The novelists who caused such a change in the Tatar literature were Gabdrakhman Absalyamov and Fatih Karim. Their literary works have a distinctly documentary beginning: both the everyday domestic troubles of war and all the details of the fulfillment of a combat task, and the way it was all planned and executed, are described with special detail. After all, only an accurate truthful description of events taken from life itself can ensure the effectiveness of literature, its educational function. Along with heroic pathos, the national character, the image of a brave and courageous Tatar man appears in the Tatar literature. The image of the Tatar soldier, the Tatar man, placed at the center of each work, appears as a model of courage, honesty, loyalty, selflessness in the struggle for the country. The "masses" were replaced by such concepts as "the Tatar people", "native land" and "Fatherland". It is not civic duty, not class struggle, but the struggle for life, for the country, for love, for the future that comes first. Thus, humanistic tendencies were strengthened in literature. They remained in Tatar literature even after the end of the war. The division of the way of life and the world into two opposite facets, defined by such values as life and death, freedom and slavery, courage and cowardice, allows the author's position to be clearly expressed. In the works that recreate the trench truth, the conversation about the spiritual power, courage, and humanity of the heroes turns into a conversation about man as a whole, about his essence, psychology, spiritual and physical capabilities, and war into the greatest tragedy invented by mankind. The novelists, tied to a specific time and place, argue about universal values. Even after the Great Patriotic War, the theme of war remains one of the main themes in Tatar literature. However, its content is changing. As we move away from this tragedy in time, the trench truth is replaced by the portrayal of war and man in other planes.

**Ключевые слова**
Татарская проза, период Великой Отечественной войны, Г. Абсалямов, Ф. Карим, документальность, психологизм, национальный характер, философичность.

**Keywords**
The Tatar prose, the period of the Great Patriotic War, G. Absalyamov, F. Karim, documentary, psychologism, national character, philosophical.

Көтелмәгәндә Бөек Ватан сугышы башлану ил тормышына, шул исәптән татар әдәбиятына да бик нык тәэсир итә: язучылар, халык белән бердәм булып, илбасарларга каршы көрәшкә күтәреләләр, кулларына корал һәм каләм алып, турыдан-туры сугышта катнашалар, фронт газеталарында эшлиләр. Өлкән яшьтәгеләр һәм сәламәтлекләре какшау аркасында фронтка китә алмаган язучылар да үзләрен һәм иҗатларын, «Барысы да фронт өчен!» дигән чакыруга буйсындырып, ил азатлыгы өчен көрәшкә багышлыйлар.

Бу чор әдәбиятында бер тема – сугыш темасы үзәктә тора. Беренче көннәрдән үк туган ил өчен изге көрәшкә өндәгән, җиңүгә ныклы ышаныч белән сугарылган шигырьләр күпләп иҗат ителә. Прозада публицистик очерк һәм кыска хикәяләр, драматургиядә – кыска пьесалар әйдәп баручы жанрларга әйләнә. Әмма беренче әсәрләрдә сугыш – мифлаштырылып, көчле һәм кыю совет солдатлары тискәре амплуада (көчсез һәм акылсыз итеп) сурәтләнгән немец сугышчыларына каршы куела. Моңа аларның авторлары – тылдагы газета-журналларда эшләүче, чын сугыш кырын күрмәгән каләм әһелләре булу да йогынты ясый. Аннары, сугыш башланган дәвердәге һәр совет кешесе кебек үк, язучылар да тиз арада дошманны җиңеп чыгуга ышана. Сугышның беренче елларында болар шактый схематик әсәрләр туура китерә.

Әмма мондый хәл озакка бармый: фронт газеталарына дип махсус язылган һәм сугышта гади кешеләр күрсәткән батырлыклар, чын ватанпәрвәрлек, югары әхлакый сыйфатлар алгы планга куеп тасвирланган публицистик мәкаләләр, очерклар пәйда була. Бу өлкәдә фронт хакыйкатен җиткерүчеләр дип без, иң беренче чиратта, Г. Әпсәләмов һәм Ф. Кәримне күрсәтә алабыз.

Габдрахман Әпсәләмов әдәбият мәйданына Бөек Ватан сугышы башланыр алдыннан гына килеп керә: М. Горький исемендәге Әдәбият институтын тәмамлаган яшь язучының 1940 елны «Киләчәк безнеке» исемле пьесасы, 1941 елны «Бәхет кояшы» дип исемләнгән беренче хикәяләр җыентыгы басылып чыга. Соцреализм кысаларында язылган беренче әсәрләрендә искене җимереп яңаны төзү барышын үзәккә куйган язучының иҗат стиле формалашуда сугыш зур роль уйный. С. Хәким 1984 елны язганча, «Әпсәләмов – тулысы белән Ватан сугышы чоры язучысы. Шул заман рухы тудырган язучы. Күтәренке рух, романтик рух. Стиленең публицистик характеры да шуннан. Сугыш һәм яшьлек, героика бергә кушылды. Заманы – романтик»[1].

Башта разведчик, аннары миномет расчеты командиры, ә соңыннан хәрби корреспондент буларак, 1941 елдан 1946 елга кадәр фронтта булган Г. Әпсәләмов бу чорда язылган күпсанлы хикәяләрендә, «Ак төннәр» (1946) повестенда гади солдатларның батырлыгы, ил азатлыгы өчен гомерен кызганмавы хакында сөйли, гадәти вакыйгаларда сугыш фаҗигасен дә, кеше күңеленең олылыгын да ачып бирә. Татар әдәбиятында фронт чынбарлыгы нәкъ менә Г. Әпсәләмов хикәяләрендә укучы игътибарына тапшырылды дисәк, ялгышмабыз. Монда язучының үзенең дә фронтта көрәшүе хәлиткеч роль уйный.

Әлбәттә, Г. Әпсәләмов иҗатында да героик пафос әйдәп бара. Әйтик, аның «Ватан улы» (1941) хикәясендә үзәккә куелган очучы Моратов истребителе белән дошман бомбардировщигына таранга бара, дошманны туган иленә үткәрми. Яки «Үлемнән көчлерәк» (1943) хикәясенең төп герое – диңгезче егет Искәндәр – дошманны «Үлем кыясына» китереп, үз гомере хисабына иптәшләрен

коткара. Язучы хикәяләрендәге гадәти булмаган сюжет, вакыйгаларның тиз агышы, геройларның да, батырлык мизгеленең дә романтик күзаллаулар яктылыгында идеаллаштырып сурәтләнүе фронт күренешләрен тергезгән әсәрләргә хас сыйфатка әверелә. Шулар белән янәшә Г. Әпсәләмов хикәяләре татар прозасына сугышны – белеп һәм җентекләп, бик вак күренешләрдә һәм детальләрдә тасвирлауны алып килә.

Язучы хикәяләрендә татар кешеләрен үзәккә куя, аларның көчле, кыю, нык булуына игътибар итә. Г. Әпсәләмов иҗатында сугыш – милли төсмер ала, гуманистик нигездә тасвирлана башлый. Рус әдәбиятында да шундый үзгәрешне күзәтеп, А. Архангельский болай ди яза: «Совет әдәбияты таләп иткән “халык массалары”ннан – “халык”ның үзенә, сыйнфый сизгерлектән – кешелеклелеккә, дуслыкка мәхәббәткә борылыш була бу»[2]. Аның фикеренчә, К. Симоновның «Ты помнишь, Алёша, дороги Смоленщины…» (1941) шигыре – шушы борылышны тәэмин иткән текстлардан саналырга тиеш.

Татар әдәбиятында шундый ук борылышны тәэмин иткән, милли геройларны фронт шартларында тасвирлаган беренче проза әсәрләрен исә Г. Әпсәләмов иҗат итә. Ул аларны татар халкының иң гүзәл сыйфатларын үзләренә туплаган шәхесләр буларак сурәтли. Әйтик, байракны дошман кулына бирмәс өчен берүзе калып көрәшкән Миңнулла Кәлимуллин – гаярь сугышчы («Байрак» (1943). Ул – күңеле җирсегәндә, «Биектә генә тауның, ай, башына, / Ат җибәрдем үлән кыркырга / Дошман алтмыш булса, дуслар җитмеш, / Нигә дошманнардан куркырга»[3] дип, йомшак тавыш белән җырлый торган ир-егет, өч көн буе Үлем үзәнендә байрак саклый. Шулай ук җырларга ярата торган, рухы һәм фикерләве белән авыл татары («Хәйбулла солдат» (1944)), финнар һөҗүмгә күтәрелсә, шул хакта хәбәр итәргә дип дошман тылына җибәрелгән Хәйбулла Актуганов, яраланып дошман кулына төшкәннән соң да, уяулыгын җуймый: солдатларның берсен үтереп, икенчесен тел итеп алып кайта. Бу юлда бөтенләй сукырайган Хәйбулланың көрәштәшләре янына кайтып җитүе үзе зур батырлык була. Әкият чигенә җиткерелгән хикәяләү ышандыра: чөнки язучы сугыш кырында гына очрый торган бик күп детальләрне һәм Хәйбулла солдатның кичерешләрен бербөтен тарих итеп тезә. Хәтта иҗади уйдырмага нигезләнгән проза әсәрләрендә дә прозаик тарафыннан документальлек тәэсире тудырылу, укучыны вакыйгаларның чынлыгына ышандыру теләге сизелә.

Иң тәэсирле хикәяләрнең берсе – «Егетнең егете» (1944) ефрейтор Әсрар Хәмидуллин характерын тергезә. Ул иптәшләре арасында тапкыр сүзе, әллә нинди әкияти вакыйгалар сөйләп, юктан кызык табып, барысын үзенә каратып торуы белән аерылып тора, «артист» кушаматы ала. Дошманны куып барганда, «Җәһәннәм тавы»ннан беренче булып төшеп, отделение өчен юл салган кыю егет, командирын коткарырга ташланып, авыр яралана: «Үземне коткарган сугышчы янына килеп иелгәндә, ул җиңе белән күзләрен каплап, кан эчендә ята иде. Мин аны юлдан читкәрәк өстери башладым. Ул гырылдаган ачулы тавыш белән:

– Кем ул, ташла мине, немецларны кыйна! – дип кычкырды. Бу – Хәмидуллин иде…»[4].

Икенче сугышта яраланып госпитальгә эләккән хикәяләүче анда ике күзе дә сукырайган Әсрарны очрата. Хәле никадәр авыр булса да, егет һаман да җор

телле, шул ук вакытта язучы аның тагын бер сыйфатын күрсәтә: үз батырлыгы турында мактана торганнардан түгел икән ул! Күзләре күрмәячәген белсә дә, аның йөрәге өметтән аерылмый: «Аннары, миңа сукыр булырга ярыймы соң, иптәш гвардия капитаны? Дошманнардан азат ителгән илемнең бәхетен күрәсе бар бит әле... Аның тавышы ышаныч һәм якты өмет белән тулы иде»[5].

Язучы һәр героеның хәтерендә гаиләсен, якын кешеләрен калкуландыра. Әйтик, бик мөһим пакет илтә барганда яраланган карт солдат Нуруллага («Зәңгәр иртә», 1945) якыннарын һәм туган җирен хәтеренә китерү көч бирә: «Нурулла ерак колхозда калган хатыны Тәнзиләне, "Әткәем кайчан кайтыр" дип тилмереп көткән биш яшьлек улы Сәлимне, чал сакаллы этисе белән карчык әнкәсен, "Абыем!" дип өзелеп хатлар язучы сеңлесе Дилбәрне, гүзәл Ыкны, киң кырларны, матур болыннарны хәтерләде һәм йөрәге яңа бер ашкыну белән тибәргә тотынды. Нурулла, актык көчен җыеп, чаңгылары өстенә күкрәге белән ятты да, шуыша башлады. Исән аягы һәм катып беткән куллары белән авыр гәүдәсен этәрде. Суда йөзгән чакта дулкыннарны башы белән сөзеп барган шикелле, йомшак карны ялан башы белән ерып барды»[6]. Шул рәвешле, үлем чигенә җиткән солдатка иң кадерле кешеләре, туган туфрагы хакындагы уйлар яшәү көче бирә. Ярату һәм өмет – җиңүгә юл биргән сыйфатлар буларак – югары күтәрелә.

Г. Әпсәләмовның документальлеккә корылган хикәяләрендә («Олаучы Абушахман», 1942; «Икенче гомер», 1942; «Төньяк балкышы», 1943; һ.б.) нык ихтыярлы, актык тамчы каннарына кадәр дошманнарга каршы көрәшүче геройлар үзәккә куела. «Үлемнән көчлерәк» (1943) хикәясендә исә «Үлем кыясы» түбәсенә финнарны алып китеп, үзенә дигән иң соңгы патронын да, «Бу патронны үземә атарга минем хакым юк. Актыккы патрон да дошманга!»[7] дип, атып бетереп, үлем хәлендә өстенә ташланган фин сугышчысын да өстерәп упкынга атылган Искәндәр батырлыгы шундыйлардан.

«Давыл» (1944) хикәясендә документальлек беренче җөмләдә чагылыш таба: «Бу вакыйга 1944 елның җәендә Рыбачийның кыргый кыялары арасында булды»[8]. Әмма шуннан соң тирән психологизм белән сугарылган әдәби әсәр башланып китә. Язучы аны гадәти булмаган ситуациягә кора. Разведчиклар сугышчан бурычын үтәгәндә, Николай Дадоновның аяклары чәрдәкләнә. Группа командиры Лобачев «арада иң көчле егет – сержант Шәүкәт Хөснуллинны», Николайны коткару бурычы куеп,ерактагы таулар аша безнекеләр ягына алып чыгарга җибәрә. Дүрт көн буе үзләренекеләр куып җитәренә ышанып хәрәкәт итсәләр дә, юлдашлар хәлдән тая. Язучы моны ышандырырлык детальләр белән гел күрсәтеп бара. «Николайның яралы аяклары бүрәнәдәй булып шештеләр. Ул, аларның сызлавына чыдый алмыйча, тырнаклары белән ташларны тырный һәм канатканчы иреннәрен тешли иде... Шәүкәт, Николай кебек үк йончымаса да, ул да ябыкты. Күзләре эчкә баттылар, борыны юкарды, йөзе йон белән капланды. Болай да сүзгә юмарт түгел иде, хәзер бөтенләй сөйләшми башлады. Хәзер ул бик еш егылгалый һәм, ничек кенә сакланмасын, барыбер Николайның яралы аяклары ташларга бәрелә иде. Мондый чакларда яралы ачы итеп кычкыра, Шәүкәт я эченнән сүгенә, я үзенең көчсезләнә баруын иптәшеннән яшерер өчен, үзенең авыр карашын ерак тауларга юнәлтеп, озак-озак шунда карап тора иде»[9]. Шул рәвешле, прозаик әлеге ике солдатка карата психологизм алымын кулланып, аларның барлык кичерешләрен ачып бара. Николай, үз үлеменнән бигрәк,

Шәүкәтне авыр хәлгә төшерүе өчен борчыла, аның өйдә көткән ике баласын да уйлый, ахыр чиктә, иптәшеннән үзен калдырып китүен сорый. Әмма Шәүкәт аны ачуланып ташлый, «Бетсәк, бергә бетәрбез», ди. «Шәүкәт, Николайның ай-ваена карамый, аны күтәрде дә җилгә, давылга каршы тагын алга китте. Бу минутта аны һичнинди көч туктата алмас иде»[10]. Николайның аягында гангрена башлана, һәм ул үзен-үзе атып үтерергә карар кыла. Әмма Шәүкәт аның патроннарын үзенә алып куйган була инде.

Язучы әсәрне уңай финалга китерми: әллә хушсыз, әллә йокыдагы иптәшен күтәреп, Шәүкәт тагын юлга кузгала. Бары тик Манара-тауны яктырткан кояш нурлары гына бу газапларның бушка китмәсен искәртә кебек.

Шул рәвешле, татар халкындагы героизмны, тугрылыкны, туган илне саклау һәм яклау омтылышының бик көчле булуын язучы гадәти булмаган ситуацияләр тудырып күрсәтә. Әйтик, «Икенче гомер» (1943) хикәясендә разведчиклар немецлар җәзалап, тере килеш утка ташлаган совет сугышчысы гәүдәсенә тап булалар. Вакыйф исемле Татарстан егете аякка баса, үзенең госпитальгә кергәндәге хәлен болай аңлата: «Мине дәвалаган врач әйтә, син ди, Гарифуллин, дөньяга икенче тапкыр тудың. Сине монда алып килгән чакта, кеше дип аталырлык бернәрсәң дә юк иде, ди... Янып, көеп беткән бер ит кисәге генә идең син, ди...»[11]. Алты айга туган авылына хәл җыярга кайтарасыларын белгәч, Вакыйф үзен фронтка җибәрүләрен сорый: «Җибәрәселәре килмәгән иде, малай, комиссарга, госпиталь начальнигына кадәр барып җиттем. Күп даулаша торгач, риза булдылар. Сине, диләр, Гарифуллин, үлем җиңә алмагач, без генә җиңә алмабыз, әйдә, синеңчә булсын, диделәр. Үзләре көләләр. Чыннан да, үзең уйлап кара, илгә кайтсам мин нишләр идем? Ял итә алыр идемме? Юк! Ә фронтта мин кирәк. Бәлки, мине коткарган иптәшләрне очратырмын. Син ничек уйлыйсың, очратырмынмы?»[12].

Шундый ук тәэсирле, тирән психологизм белән сугарылган «Кызыл ракета» (1944) хикәясендә арсланнарча сугышып, дошман кулына бирелмәс өчен үзләрен граната белән шартлатырга әзер, үлем алдында торган бер взвод сугышчыларының кичерешләре, уй-ниятләре җентекләп тасвирлана. «Япон диңгезендә» (1945) хикәясендә «Амур» пароходын батырган японнар 12 көн диңгездә чайкалып, исән калган дүрт солдатка ялган сөйләргә тәкъдим итә, риза булмасалар, кабат шул көймәләренә утыртып диңгезгә ташлаячакларын әйтәләр. Җавап бер: «Утыртыгыз! Бер түгел, ун тапкыр утыртыгыз! Ләкин без Ватаныбызны сатмыйбыз! Без бөтен нәрсәбезне югалттык, ләкин вөҗданыбызны югалмадык, – дип кычкырды Савельев. Кызу канлы Хәйдәр тагын да ачырак сүз өстәде»[13].

Бу җәзаның коточкыч авырлыгын күрсәтер өчен, язучы хикәя башында диңгезчеләрнең берсе радист Хәйдәр белән Наҗиянең, инженер Сергей белән Надежданың тирән мәхәббәтен сурәтләп уза. 12 көн тозлы диңгездә яшәү белән үлем арасында көрәшкәннән соң, кабат шунда ташлау турында хикәяләүче исеменнән мондый сүзләр әйтелә: «Бу – коточкыч хәл иде. Шул хәтле кичерешләрдән соң, яңадан диңгезгә ташлану үлем ачысыннан да авыррак иде. Әгәр дә диңгезчеләрне кыйнау, ату, асу белән янасалар да, аларга бу кадәр үк куркыныч булмас иде. Бу коточкыч җәзаны уйлап табу өчен иң явыз садист, кеше психологиясе белән уйнаучы иң кабахәт палач булырга кирәк иде. Ләкин совет кешеләре Ватан намына бу коточкыч җәзаны да кабул иттеләр»[14].

Мондый хикәяләрдә гадәттән тыш шартларга куелган кешеләрнең рухи һәм психологик ныклыгы, туган илгә тугрылыгы, кешелеклелек сыйфаты алга чыга. Нәтиҗәдә әсәрләр гомумән кеше, аның бөеклеге, гуманизм турында сөйләүче текстларга әвереләләр.

Язучы патриотизмны кайчак бөтенләй көтелмәгән яктан тасвирлый. «Ана йөрәге» (1945) хикәясендә ул шулай. Сәрбиҗамал белән Галимулла гаиләдә ике кыз үстерәләр. Әле сугыш башланганчы ук якты дөнья белән хушлашкан Галимулла, үлем алдыннан хатынына васыять әйткәндә, болай ди: «Малай минем нәселемне дәвам иттерер иде, кирәк була калса, газиз Ватанын корал көче белән дә саклар иде. Кызлар солдат була алмый бит»[15].

Сугыш башлангач, бу фикер Сәрбиҗамалның да күңеленә килә. Гаилә дуслары Наталья Сергеевнаның биш улы фронтка киткәндә, ананың аңында мондый уйлар бөтерелә: «Хәзер Сәрби апа үз улы юклыгының никадәр ачы булуын бөтен күңеле белән сизә иде. Ил алдында, кешеләр алдында, Наталья Сергеевна алдында аңа ничектер уңайсыз, хәтта оят кебек тоелды. Сәрби апа үзен бик-бик бәхетсез итеп санады. Балалар асрап та, балаларың изге эшкә ярамагач, ана бәгыре ничек көймәсен дә, ничек телгәләнмәсен! Көйде дә, телгәләнде дә. Ул кимсенеп, бөкрәеп, кечерәеп өенә кайтты һәм кич буе үзен кая куярга белмичә аптырап йөрде»[16].

Алга таба язучы каләме ананың олы кызы Хәнифәнең – хәрби заводта эшли башлавын, кече кызы Хәдичәнең партизаннар отрядына китүен тасвирлый. Хәдичә әнисенә мондый сүзләр әйтә: «Илне саклау барыбызның да эше ул, әнкәй. Туган ил ирләргә дә, кызларга да бертигез кадерле. Ансыз без яши алмыйбыз»[17].

Шул рәвешле, Г. Әпсәләмов, фронтта көрәшеп, татар әдәбиятына окоп хакыйкатен алып кергән беренче прозаик була. Сугыш беткәч, ул вакыйгаларны зуррак жанрда – романда, геройларның гаилә-нәселе, мохите, сугышка кадәрге тормышын фронт вакыйгалары белән үреп тасвирлауга килә, «Алтын йолдыз» (1948), «Газинур» (1953), «Мәңгелек кеше» (1960) романнары шундыйлардан. «Г. Әпсәләмов әсәрләрендә татар солдатлары, татар кешеләре батырлыгына дан җырлана»[18] диюе белән Ә. Баянов хаклы: гранатасы белән ташланып, немец танкын шартлаткан Газинур Гафиятуллин, Бухенвальд үлем лагеренда бунт әзерләгән Бакый Назимов кебек геройлар эпос герое структурасында иҗат ителеп, милли герой, көчле кеше, тормышны үзгәртүче генә түгел, бәлки үлемне җиңгән романтик образ буларак тәкъдим ителәләр[19]. Әмма романнарда окоп хакыйкате язучының хикәяләрендәге кебек беренче планга куелмый. Күрәсең, бу яктан кече жанрның үз өстенлекләре була.

Хикәя жанры белән янәшә, Бөек Ватан сугышы чорында ук фронт тормышын чагылдырган әсәрләр повесть жанрында да тәкъдим ителә: бу Ф. Кәрим исеме белән бәйле.

Фатих Кәрим (Фатих Әхмәтвәли улы Кәримов, 1909-1945) әдәбиятка 1920 еллар ахырында ук килә. 1938 елның 3 гыйнварында нахакка кулга алынып, дүрт елга сузылган сәяси тоткынлык чорында да ул шигырь язудан туктамый. Иң зур омтылышы – ил алдында гаепсезлеген раслап, үзен яладан йолып алу булган шагыйрь, «үзе теләп» фронтка китү шарты белән, 1941 елның 1 декабрендә иреккә чыгарыла. Ф. Кәримнең окопта, блиндажларда язылган 150 шигыре, 8 поэмасы аның гражданлык батырлыгы үрнәге булып тора. Фронтта ул «Разведчик язмалары» (1942), «Язгы төндә» (1944) дигән ике повесть иҗат итә.

«Разведчик язмалары» мин исеменнән хикәяләүче һәм төрекмән егете Акморатның, дошман урнашкан нокталарны картага төшерү өчен, немецлар яулап алган территориягә разведка ясауларын тасвирлый. Тирә-яктагы хәл-әхвәлне ачыклау өчен, хикәяләүче авыл читендәге карчыкка керә. Улы партизаннар арасына киткән карчык сугышка кадәрге тормышны сагынып искә ала, немецлар авылга чыкканны хәбәр итеп, улап узып китә торган эт хакында сөйли. Шулай язучы, әйтерсең лә, кешеләр генә түгел, җан ияләренең дә дошманны яратмавын искәртә.

Инде сугышчан бурычны үтәп, кайтырга чыккан разведчиклар иртә белән көтелмәгән хәлгә очрый. 20-ләп немец солдаты авылдан хатын-кыз һәм балаларны кырга куа. Әлеге күренешне яшеренеп күзәтеп торган малайны күреп, разведчиклар моның сәбәбен сорашалар. Партизан хатыннары булганга, ирләренең кайда икәннәрен әйттерер өчен шулай йөртәләр икән. Малай исә, әнисе белән сеңлесе өстенә пулялар яуганны күреп, качкан урыныннан йөгереп чыга, һәлак була. Әлбәттә, окоп хакыйкате сугышчан бурыч үтәргә килгән разведчикларга шушы урында бу фаҗигагә чик куярга, хатыннар һәм балаларны коткарырга ирек бирми.

Күз алдында вәхшилек эшләгән солдатлар китүгә, хикәяләүче аранга керә. Андагы үлеп ятучы хатыннар арасында бәләкәй Люданың тере икәнен күреп ала. Немецларга һөҗүм итәргә рөхсәт булмаган, разведка мәгълүматларын кайтарып җиткерергә ашыккан солдатлар Люданы үзләре белән алалар. Фашистларның аранга ут төртүен сөйләп, автор мондый нәтиҗә ясый: «Дөньяга ут төрткән, ләкин үзләре шул утта янып көлгә әйләнәчәк вәхшиләр бөек цивилизация чорының ям-ямнары, аналар һәм сабый балаларның үле гәүдәләрен утта яндырып, көйгән адәм ите исеннән ләззәтләнеп утыралар»[20].

Хикәяләүче белән Акморатка җайлы гына кайтып җитәргә язмаган була: башта һөҗүмгә әзерләнгән өч немецны кырып салсалар да, оборона сызыгында аларны сизеп алалар. Пулеметтан атыш башлана, Акморат үлә. Икенче көнне таңда, юлдашын күмгәндә, язучы аның исеменнән мондый сүзләр әйттерә: «Без Акморатны кабергә төшердек. Төшерүебез булды, еракта, дошман тылында, каты гөрселдәгән тавышлар ишетелде. Бөтенебез дә борылып шул якка күз салдык. Акморат белән икәү планын төшергән урман эченнән ургылып-ургылып ялкын катнаш кара төтен күтәрелә, урманның көле күккә оча иде. Минем йөрәк әллә ни эшләп, җилкенеп китте. Тын гына борылып, мин кабердә яткан Акморатка күз төшердем. Түзмәдем, тирән дулкынлану белән Акморатка – сугыш кырындагы иң якын дустыма – соңгы аерылышу сүзләремне әйттем:

– Тыныч йокла, иптәш! Үлсәк тә, бушка үлмибез без. Каһәрле дошманның көлен күккә очырып үләбез. Күрәсеңме, без синең белән эзебезне калдырып үткән урманда, дошман тылындагы урманда, дошман, аның көче, коралы белән тутырылган складлары бер-бер артлы шартлыйлар. Алар кара төтен булып күккә күтәреләләр. Җил аны ерактагы таулар артына илтеп тарата, юк итә.

Ә без калабыз! Ата-аналар, туганнар, иптәшләр, якын дуслар кала!

Сөйгән халык кала. Туган ил кала!..»[21]

Икенче повесть, «Язгы төндә», шулай ук фронт разведкасындагы бер сугышчан бурыч – «тел» алып кайту йөкләмәсен үтәүне сурәтли. Бу эшкә җибәрелгән Цветков взводының һәр сугышчысын язучы үз холкы, үз тарихы белән тергезә. Сугышчылар арасында үзара хөрмәт, уен-көлке тасвирлана. Иптәшләре үзеннән

шаяртырга яратса да, сазлыкны кичкәндә су тирәнәйгәч, алып гәүдәле Бугаев кечкенә буйлы Торсынбайны күтәреп бара. Фәттах ялгышып Торсынбайны, немец офицеры белән бергә, капчыкка тыгып куеп, иптәшләре аны югалткач та, Бугаев дустын көтеп торачагын әйтә. Яралы Бугаевны коткарырга исә Торсынбай китә. Шул рәвешле, прозаик үзара ярдәмләшү, дуслык хакында сөйли. Яралы солдатны госпитальгә озаткач, Торсынбай белән Фәттах арасында сөйләшү булып ала. «Ай Бугаев, Бугаев, бик ярата идем мин аны. Ул үзе дә мине ярата иде бит, шулай бит, Фәттах ага» дигән сорауга сержант: «Бугаев сине туганы кебек ярата иде»[22], – дип җавап бирә.

Җылы юмор, сугышчылар арасында үзара шаярышу Г. Әпсәләмов һәм Ф. Кәрим әсәрләренең һәркайсында диярлек катнаша. Алар солдатларга һәр секундта сагалап торган үлем куркынычын җиңәргә ярдәм итәләр.

Язучы үзәккә Идел буе егете өлкән сержант Фәттах Исламовны куя. Аның уй-кичерешләрен күзәтеп бара: «Фәттахның яшьлектән һич аерыласы килми, яшьлекне озак вакытларга сузасы килә иде. Аның әле берәр институтның механика факультетында укып чыгасы, бөтен Советлар Союзын йөреп чыгасы, Ак һәм Кара диңгезләрдә йөзәсе, Мәскәү, Ленинградларда буласы бар иде. Менә хәзер алар барысы да өзелделәр. Озаккамы? Тормышка, сугыш хакыйкатенә нигә, ачык күз белән карап, дөресен әйтмәскә? Бәлки, ул бүгенге заданиедән үк әйләнеп кайтмас. Бу курку түгел, бу – һәр солдатның башына килә торган көндәлек гади уй. Бу уй башында еш чуалганга күрә дә солдатның яшисе килүе көчле. Үзенең гомерен чикләргә кул сузучыларны аеруча күралмавы көчле. Нинди матур иде бит бу тормыш! Аның агымын җимерергә кем сәбәпче булды? Фашист Гитлер!»[23]

Г. Әпсәләмов әсәрләре кебек үк, Ф. Кәрим повестьлары да сугышны гомумкешелек биеклегеннән тасвирлавы белән үзенчәлекле. Бу хакта Р. Ш. Сарчин сүзләрен кабатлау урынлы булыр: «Фатих Кәрим әсәрләрендә гәүдәләнгән фронт еллары картиналары, сугыш белән тынычлыкның, тормыш белән үлемнең «мәңгелек» каршылыгына кадәр күтәрелеп, авторны кеше рухының һәм яшәешнең тирәнлекләрен колачларлык чын философ итеп күз алдына китерәләр. Ф. Кәримнең сугыш елларындагы әдәби күзаллаулары аның иҗатын шул елларда әдәбиятының әйдәп баручы иҗади күренешләре сыйфатында бәяләргә мөмкинлек бирә»[24].

Г. Әпсәләмовның «Ак төннәр» (1946) повесте сугыш тәмамланганнан соң языла. Әмма вакыйгалылык ягыннан ул окоп хакыйкатен тасвирлаган әсәрләр белән бер рәттән тора. Монда да ерак Карелиядә, ак төннәр вакытында Валзама күперен шартлатырга киткән минерлар группасының сугышчан бурычны башкарып чыгуы күзәтелә. Әмма әсәрдә моңа кадәр күтәрелмәгән бер герой күренә: полк улы Җиһангир Мөбарәкшин ул. 1941 елның көзендә качып эшелонга кереп утырган малай шушы полкта кала, солдатларга үз балаларын искә төшереп, сугыш һөнәренә өйрәнә. Бала сугышта өлкәннәр булдыра алмаганны да башкарырга сәләтле: Җиһангир тарихы шуны күрсәтә. Әмма мондый корбан кирәкме соң? Әлеге сорауга язучы «кирәк» дип җавап бирә, тик бу ноктада тукталмый.

Әлбәттә, сугыш шартларында үскән баланың күңеле, психикасы бик нык үзгәрә. Язучы моны Җиһангирның, Саша Володаров белән дошман кулына төшкәч, үзе генә качып китүе, аннары иптәшен коткарырга омтылуы вакыйгаларында бик ачык күрсәтелә. «“Юк, мин иптәшемне ташлап китә алмыйм...

Үлсәк, бергә үлик", дип уйлый Җиһангир. Әмма бу фикере дә очланып ныгырга өлгерми, миенең кайсыдыр почмагыннан яңадан баягы уйлары агып киләләр. "Үләргә кайчан да соң түгел"...»[25] Бала яшәү белән үлем сынавы арасына куела, аларның берсен үзе сайлап алырга тиеш була.

Качу шатлыгы кичергән Җиһангир, аңына килүгә, Сашаны коткарырга ташлана, әмма кабат көчле каршылыкка очрый, аңын җуя: «Саша, кадерлем, гафу ит! – дип пышылдады ул кипкән иреннәре белән һәм, буш автоматын аяк астына ташлап, үзе дә үлән өстенә ауды. Һичкайчан, хәтта әнисе үлгәч тә яшь чыкмаган күзләреннән кайнар яшь бөртекләре бәреп чыкты һәм ул, тыела алмыйча, кыз бала кебек үкереп елап җибәрде. Капитан Разумов, Кауров, Опанас Грай һәм барлык сугышчан иптәшләре аңардан йөз чөерәчәкләр. Комсомол җыелышында бөтен кеше алдында аңа: "Иптәшеңне ташлап киткәнсең! Куркак җан! Син безнең ышанычны аклый алмадың!" дип әйтәчәкләр. Нинди хурлык!»[26] Алга таба да язучы малайның шушы хактагы уй-кичерешләрен җентекләп күрсәтеп бара. Үз дуслары янына килеп җиткәч тә, өлкән иптәшләрнең малайны сатлык дип атавы, аны ачуланулары, аннары гына дөреслекне ишетүләре күрсәтелә. Шул рәвешле, язучы сугышның балалар алдына үтәп чыга алмаслык таләпләр куюын ача. Шуның белән, әйтерсең лә, кан коешны башка бер позициядән – балаларның киләчәге, илнең киләчәге хакындагы уйланулар позициясеннән дә – кире кага.

Повесть Ташкентта дәваланып ятучы һәм иптәшләре янына ашкынган Бугаевтан хат килү белән тәгәлләнә. Туган илен, халкын һәркем сакларга тиеш, дошманга каршы көрәштә, бердәм булганда гына, җиңүне тизрәк якынайтырга мөмкин дигән гомуми фикер һәр әсәрдә диярлек чагылыш таба. Г. Әпсәләмов та, Ф. Кәрим дә аны взводта төрле милләт вәкилләре булуда, аларның үзара якын мөнәсәбәтендә дә ачыклыйлар.

Героик пафос белән бергә, татар әдәбиятында милли характер, батыр һәм кыю татар кешесе образы калкулана. Бу социалистик реализм таләпләре кысасында интернациональлеккә йөз тоткан әдәбиятыбызны тулысынча үзгәртә. Һәр әсәрнең үзәгенә куелган татар солдаты, татар кешесе образы кыюлык, намуслылык, тугрылык, ил өчен үз-үзеңне аямау югарылыгына күтәрелә, горурланырлык итеп идеаллаштырыла. Сугышка кадәрге совет әдәбиятындагы «массалар» урынына – «татар халкы», «туган җир», «Ватан» кебек төшенчәләр килә. Гражданлык бурычы, сыйнфый көрәш түгел, яшәү, ил, мәхәббәт, киләчәк өчен көрәшү алга чыга. Шул рәвешле, әдәбиятта гуманистик тенденция ныгый. Болар инде сугыш беткәннән соң да татар әдәбиятында урнашып калалар.

Тормышны, дөнья сурәтен ике капма-каршы чиккә – яшәү һәм үлем, азатлык һәм коллык, батырлык һәм куркаклык кебек кыйммәтләр белән билгеләнә торган чикләргә аеру исә автор позициясен ачык белдерергә ярдәм итә. Сугышны – олы бер фаҗига, солдатны шәхес итеп карау прозада психологизмны һәм фәлсәфилекне тирәнәйтә. Окоп хакыйкатен тергезгән әсәрләрдә геройларның рухи куәте, батырлыгы, кешелеклелеге турында сөйләшү – гомумән кеше, аның җисеме, асылы, психологиясе, рухи һәм физик мөмкинлекләре хакында сөйләшүгә, сугыш исә – кешелек дөньясы уйлап тапкан иң олы фаҗигагә кадәр үсә. Сугыш вакыйгалары белән төгәл вакытка һәм урынга бәйләнгән прозаиклар гомумкешелек кыйммәтләре турында фикер йөртәләр.

Бөек Ватан сугышыннан соң да татар әдәбиятында сугыш темасы иң мөһимнәрдән булып кала. Әмма аның эчтәлеге үзгәрә. Вакыт ягыннан әлеге фаҗигадән ераклашкан саен, окоп хакыйкате урынына сугышны һәм кешене башка яссылыкларда сурәтләү килә.

## ИСКӘРМӘЛӘР:


1. *Хәким С.* Батырлыкка чакырган кеше ... // Ак чәчәкләр бүләк итте. Г. Әпсәләмов турында истәлекләр. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2001. – 43 б.
2. *Архангельский А.* «С войной покончили мы счёты»: как менялись книги о Великой Отечественной. Электронный ресурс. Режим доступа: https://polka.academy/materials/774 (дата обращения: 12 января 2025 г.).
3. *Әпсәләмов Г.* Зәңгәр кыя: хикәяләр җыентыгы. – Казан: Татгосиздат, 1947. – Б. 67.
4. Шунда ук. – Б. 136.
5. Шунда ук. – Б. 147.
6. Шунда ук. – Б. 125-126.
7. *Әпсәләмов Г.* Ак төннәр: повесть һәм хикәяләр. – Казан: Татгосиздат, яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе, 1953. – Б. 116.
8. *Әпсәләмов Г.* Зәңгәр кыя... – Б. 3.
9. Шунда ук. – Б. 5-6.
10. Шунда ук. – Б. 15.
11. *Әпсәләмов Г.* Ак төннәр... – Б. 110.
12. Шунда ук. – Б. 111.
13. Шунда ук. – Б. 178.
14. Шунда ук. – Б. 177.
15. Шунда ук. – Б. 91-92.
16. Шунда ук. – Б. 98.
17. Шунда ук. – Б. 107.
18. *Баянов Ә.* Кыялар исән кала // Ак чәчәкләр бүләк итте. Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр. – Казан: “Мәгариф” нәшр., 2001. – 63 б.
19. *Заһидуллина Д.* Габдрахман Әпсәләмов прозасы: көчле кеше фәлсәфәсе аша романтизмга // 1960-1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр: монография. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2015. – Б. 212-222.
20. *Кәрим Ф.* Разведчик язмалары: шигырьләр, поэмалар, баллада, повестьлар, пьеса. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2024. – Б. 205.
21. Шунда ук. – Б. 212-213.
22. Шунда ук. – Б. 261.
23. Шунда ук. – Б. 234-235.
24. *Сарчин Р. Ш.* Фатих Карим: к 110-летию со дня рождения поэта. Электронный ресурс. Режим доступа: https://stihi.ru/2019/01/14/3296 (дата обращения: 12 января 2025 г.).
25. *Әпсәләмов Г.* Ак төннәр... – Б. 46.
26. Шунда ук. – Б. 66.


### Әдәбият исемлеге


Ак чәчәкләр бүләк итте. Габдрахман Әпсәләмов турында истәлекләр / Төз. *Г. Мөхәммәдова*. – Казан: «Мәгариф» нәшр., 2001. – 159 б.

*Архангельский А.* «С войной покончили мы счёты»: как менялись книги о Великой Отечественной. Электронный ресурс. Режим доступа: https://polka.academy/materials/774

*Кәрим Ф.* Разведчик язмалары: шигырьләр, поэмалар, баллада, повестьлар, пьеса. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2024. – 334 б.

*Сарчин Р. Ш.* Фатих Карим: к 110-летию со дня рождения поэта. Электронный ресурс. Режим доступа: *https://stihi.ru/2019/01/14/3296*

## References

*Ak chechekler bulek itte: Gabdrakhman Apsalamov turynda istelekler. Toz. G. Mohammadeva* [He gave the white flowers. The Memories about Gabdrakhman Absalyamov. Compiled by G. Mukhamedova]. Kazan, "Megarif" publ., 2001, 159 p.

*Arkhangel'skii A. "S voinoi pokonchili my schety": kak menialis' knigi o Velikoi Otechestvennoi* ["With the war we have finished our accounts": how books about the Great Patriotic War changed]. URL: *https://polka.academy/materials/774*

Karim F. *Razvedchik iazmalary: shigyr'ler, poemalar, ballada, povest'lar, p'esa.* [The Scout's articles: poems, poems, ballads, novellas, plays]. Kazan: Tatar. kit. nashr. publ., 2024, 334 p.

*Sarchin R. Sh. Fatikh Karim: k 110-letiiu so dnia rozhdeniia poeta* [Fatih Karim: to the 110th anniversary of the poet's birth]. URL: *https://stihi.ru/2019/01/14/3296*

## Сведения об авторе

***Загидуллина Дания Фатиховна,*** доктор филологических наук, профессор, главный научный сотрудник отдела литературоведения Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ, e-mail: zagik63@mail.ru

***Daniya F. Zagidullina***, Doctor of Philology, Professor, Chief Scientist of the Department of Literary Studies of the G. Ibragimov Institute of Language, Literature and Art, the Academy of Sciences of the Republic of Tatarstan, e-mail: zagik63@mail.ru

## В редакцию статья поступила 30.01.2025, опубликована:

*Заһидуллина Д. Ф.* Бөек Ватан сугышы чоры прозасында «окоп хакыйкате» // Гасырлар авазы – Эхо веков Echo of centuries. – 2025. – № 1. – С. 20-31.

## Submitted on 30.01.2025, published:

Zagidullina D. F. *Boek Vatan sugyshy chory prozasynda "okop khakyikate"* ["Trench Truth" in the prose of the Great Patriotic War period]. IN: *Gasyrlar avazy – Eho vekov* [Echo of centuries], 2025, no. 1, pp. 20-31.